**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы № 113 17 сентябрь 2018 ел

Чубар-Абдул авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 131номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгының 07сентябрь 2018 елда чыккан 14 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 07 сентябрь елда чыккан 112 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча ноябрь 2018 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 300 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   1) Авыл эчендәге юлларны ремонтлау
      - Буралы авылында Җәлил, Октябрь Мәктәп урамнарын юлны щебенка белән каплау, Чубар-Абдул авылында Совет, Комсомол, Яшьләр урамнарын юлны щебенка белән каплау);
   2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләренраслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
      - Мәндәй авылына балалар мәйданчыгы алу һәм урнаштыру;
   3) Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру:
      - Мәндәй авылында футбол кыры төзелеше

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны районның “Маяк” газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
4. Карар газетада бастырылып чыккан соң үз көченә керә.

Рәис: Н.А.Фәтхетдинов